КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 март г.Казань № 233

Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 март, 233 нче
карары белән расланды

Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен
финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан
башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының шәһәр округлары һәм муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – муниципаль берәмлекләр, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында түбәндәгеләргә бирелә:

шәһәр округларының чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен шәһәр округлары бюджетларына;

җирлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында, муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына муниципаль районнар бюджетларыннан алга таба бирү өчен муниципаль районнар бюджетларына.

3. Башка бюджетара трансфертлар квартал саен, тиешле финанс елында үткән кварталдан соң килүче айның 30ына кадәр, шәһәр округлары һәм муниципаль районнар бюджетларына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатлар өчен күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә бирелә.

4. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларның бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

6. Тиешле квартал өчен i-муниципаль берәмлеккә башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТ_i^{кв} = НПД_i^{год} – НПД_i^{пт},$$

монда:

$МТ_i^{кв}$ – тиешле квартал өчен i-муниципаль берәмлеккә башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

$НПД_i^{ел}$ – i-муниципаль берәмлек территориясеннән Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән кергән һөнәри керемгә салым суммасы, ел башыннан арта бара торган йомгак белән, сум;

$НПД_i^{пт}$ – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән i-муниципаль берәмлек бюджетына кергән, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында элегрәк исәпкә алынган һөнәри керемгә салым суммасы, сум.

7. Түбәндәгеләргә башка бюджетара трансфертлар бирү шарты:

шәһәр округы бюджетына – шәһәр округының башка бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен билгели торган, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән хокукый акты булу;

муниципаль район бюджетына – муниципаль районның муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү буенча муниципаль районның чыгым йөкләмәсен билгели торган, башка бюджетара трансфертлар бирү шартын күздә тота торган, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән хокукый акты булу – җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен билгели торган норматив хокукый акты булу.

8. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан шәһәр округлары, муниципаль районнар бюджетларына җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган территориаль органнар исәпләренә күчерелә.

9. Шәһәр округының, муниципаль районның башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) башка бюджетара трансфертларны файдалану турындагы хисапны Министрлык билгеләгән форма буенча һәм тәртиптә Министрлыкка кертә.

10. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына бу Тәртип нигезендә алынган һәм файдаланылмый калган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмый калган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдәге акча агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган шәһәр округы, муниципаль район бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен элегрәк бирелгән шәһәр округы, муниципаль район бюджеты керемenә кире кайтарылырга мөмкин.

Бу Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Министрлык билгеләгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

11. Башкарма комитет һәм вазыйфаи затлар кертелә торган хисаплар мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлүе өчен законнар нигезендә җавап бирә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Бу Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.